ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17 октябрь 2024 ел № 6846

2025 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең туризм-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 99 статьясы, Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең туризм-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 27 мартындагы 1540 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. 2025 елга расларга:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең туризм-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү

программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны кушымтада каралганча;

2) туризм-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарга төзәтмә кертү коэффициентын 0,75 күләмендә.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә туризм-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларын һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф оешмаларын финанслауны әлеге карарның 1 пунктында каралган норматив чыгымнарга туры китереп тәэмин итәргә.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2024 елның 17 октябрендәге
6846 номерлы карарына
кушымта

2025 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең туризм-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күп профильле мәгариф оешмаларында өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнар

| Өстәмә белем бирү программасының юнәлеше | Территориаль дислокациясе | Норматив чыгымнар, елына бер укучыга сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Сәнгать-эстетика | шәһәр җирлеге | 8 280 | 15 333 | 18 399 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 8 179 | 15 145 | 18 174 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 8 583 | 15 895 | 19 074 |
| Туризм-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 8 381 | 15 520 | 18 624 |
| Экология-биология | шәһәр җирлеге | 8 381 | 15 520 | 18 624 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 8 381 | 15 520 | 18 624 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 7 976 | 14 771 | 17 725 |
| Социаль-икътисадый | шәһәр җирлеге | 7 976 | 14 771 | 17 725 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 8 381 | 15 520 | 18 624 |

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы — Г.А. Шәфыйкова

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ